# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Пыжмара авыл җирлеге составына керүче Әтнә торак пункты

5 декабрь 2021 ел № 10

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 - ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56нчы маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында " 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 нче маддәсе нигезендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Әтнә торак пунктында гражданнар җыены карар итте:

1. «2022 елда гражданнарның үзара салымын Балтач муниципаль районы Пыжмара авыл җирлегенең Әтнә торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән 18 яшькә җиткән һәр кешедән 650 (Алты йөз илле) сум күләмендә кертергә. (I төркем инвалидлар өчен; үз-үзләренә хезмәт күрсәтә алмый торган гражданнар; балигъ булмаган балалар тәрбияләүче ялгыз ата-аналар (законлы вәкилләр); Россия Армиясе сафларында вакытлы һәм контракт хезмәте үтүче хәрби хезмәткә чакырылучыларга 90% күләмендә ташлама каралган).

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә, түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

- Әтнә авылы чишмәсе территориясен чистарту һәм повильон ремонтлау белән чишмәне төзекләндерү;
- Әтнә авылының Комсомол урамы буенча ике күперне төзекләндерү, юлларны ремонтлау һәм янәшәдәге территорияне агачлардан һәм куаклардан чистарту;
- комплектлау җайланмалары булган дүрт янгын колонкасы сатып алу.»

3. Җыен нәтиҗәләрен Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Пыжмара авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында, Балтач муниципаль районы сайтында baltasi.tatarstsn.ru урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче:
ТР Балтач муниципаль районы
Пыжмара авыл җирлеге башлыгы Р. Х. Җәләев